КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 2 март г.Казань № 113

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәгарифкә ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2018 ел, 29 октябрь, 961 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2021 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәгарифкә ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2018 ел, 29 октябрь, 961 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацында җөмлә башына «2019 – 2021 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган 2019 – 2021 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәгарифкә ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру концепциясендә:

II бүлекнең унынчы – егерме дүртенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«III. Татарстан Республикасында урнашкан, «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәгарифкә ярдәм күрсәтү чаралары комплексын тормышка ашыру (шул исәптән федераль бюджеттан финанслашу исәбеннән) планлаштырыла торган оешмалар мәйданчыклары тасвирламасы**

Ишетү, күрү, сөйләм бозылышы, аутистик спектр бозылышы, терәк-хәрәкәт аппараты бозылышы, интеллект бозылышы (акылга зәгыйфь) булган балалар белән эшләү системасын үстерү 2019 елда сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 17 гомуми белем бирү оешмасы базасында ресурс үзәкләрен төзү юлы белән оештыру күздә тотыла:

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 172 нче мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 75 нче мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 87 нче мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Лаеш интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Е.Г.Ласточкина исемендәге Казан интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Бөгелмә интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Алабуга интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Түбән Кама интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 88 нче мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 7 нче интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 89 нчы башлангыч мәктәбе – балалар бакчасы» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Казан шәһәренең 4 нче интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әлмәт интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Яр Чаллы шәһәренең 86 нчы «Өмет» интернат мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әлмәт шәһәренең 19 нчы мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Чистай шәһәренең 10 нчы мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Түбән Кама шәһәренең «Надежда» интернат мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе.

2019 елның 1 гыйнвары хәленә карата әлеге учреждениеләрдә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучы тәрбияләнүчеләрнең гомуми саны 2 263 кеше тәшкил итә, шулардан:

203 мәктәп укучысы өйдә укый,

216 мәктәп укучысы мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча укый.

Белем алучыларның статистикасы (нозологияләр буенча) 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

Белем алучыларның статистикасы (нозологияләр буенча)

| Учреждение исеме | 2018 – 2019 еллар | | Муниципаль берәмлек |
|---|---|---|---|
| | Учрежде-ниеләр саны | Укучылар саны | |
| Барлык мәктәпләр һәм интернат мәктәпләр, шул исәптән: | 17 | 2 263 | |
| күрү сәләте бозылган | 4 | 614 | Яр Чаллы, Казан шәһәрләре, Лаеш районы |
| чукраклар, начар ишетүчеләр һәм соңрак чукракланганнар өчен | 5 | 497 | Бөгелмә, Алабуга, Яр Чаллы, Түбән Кама, Казан шәһәрләре |
| полиомиелит һәм балалар церебраль параличы салган зыяннар белән | 4 | 480 | Әлмәт, Яр Чаллы, Казан шәһәрләре |
| сөйләмендә җитди бозылышлары булган | 2 | 301 | Яр Чаллы, Казан шәһәрләре |
| интеллектында бозылышы (акылга зәгыйфь) булган | 2 | 368 | Әлмәт, Чистай шәһәрләре |

Ресурс үзәкләрендә укытучы-дефектолог, психолог, балалар белән эшләү буенча дефектолог, технология кабинетлары, эшчәнлек төрләре буенча кабинетларны брендлы җиһазлар белән җиһазландырылган өстәмә белем бирү кабинетларының эшләве каралган.

Үсешендә катлаулы җитешсезлекләре булган балалар белән эшләү системасын камилләштерү максаты белән 17 мәктәп базасында «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» проектын гамәлгә ашыру кысаларында ресурс үзәкләрен төзү оештырыла.

«Республика психологик-медик-педагогик консультациясе» дәүләт казна учреждениесе мониторингы нәтиҗәләренә анализ үткәрү катлаулы

җитешсезлекләре, күпсанлы бозылышлары булган (соматик авырулары һәм балалар церебраль параличы булган начар күрүчеләр, үсешендә тоткарлыгы булган һәм таяну-хәрәкәт аппараты бозылган сукырлар, сөйләмендә катлаулы бозылышлары булган сукырлар һәм начар күрүчеләр һ.б.) балалар санының ел саен артуын күрсәтә (2 нче таблица).

2 нче таблица

«Республика психологик-медик-педагогик консультациясе» дәүләт казна учреждениесе мониторингы нәтиҗәләренә анализ

| Балалар категорияләре | 2017 – 2018 еллар | 2018 – 2019 еллар |
|---|---|---|
| Инвалидлыгы булган балалар | 114 | 127 |
| Начар күрүчеләр | 134 | 149 |
| Сукырлар | 50 | 50 |
| Барлыгы, | 184 | 199 |
| шулардан: | | |
| соматик авырулары булган начар күрүчеләр | 132 | 147 |
| соматик авырулары булган сукырлар | 50 | 50 |
| сөйләмендә бозылышлары булган начар күрүчеләр | 41 | 48 |
| сөйләмендә бозылышлары булган сукырлар | 22 | 25 |
| саңгыраулар һәм начар ишетүчеләр | 6 | 7 |
| терәк-хәрәкәт аппараты авырулары (балалар церебраль параличы) булган | 27 | 39 |
| психик үсешендә тоткарлыгы булган начар күрүчеләр һәм сукырлар | 29 | 31 |

Төзәтү мәктәбенең тагын төп бурычларының берсе җәмгыятьтә алга таба социальләшүгә һәм интеграцияләнүгә сәләтле социаль юнәлешле шәхес формалаштыру, анда төзәтү-үстерү эшен алып баруга аерым игътибар бирелә, балалар өчен төрле юнәлешләрдә алып барыла торган түбәндәге дәресләр оештырыла:

спорт-савыктыру;
интеллектуаль;
социаль;
мәдәни-әхлакый;
күз күрү сәләтен үстерү;
мимика һәм пантомимиканы үстерү;
вак моториканы үстерү;
логопедик дәресләр.

Белем алучылар дефектның катлаулылыгын исәпкә алып сайлап алына торган хезмәт юнәлешләренең беренчел күнекмәләрен уңышлы үзләштерә.

Белем алучыларның үсешен индивидуаль төзәтү һөнәри юнәлеш эше системасын үстерү кысаларында да оештырыла, ул тулаем укыту программаларын һәм укыту-тәрбия барышын һөнәри юнәлеш белән тәэмин итү, системалы, квалификацияле һәм комплекслы һөнәри юнәлеш эшен үткәрү, укучыларның индивидуаль мәнфәгатьләрен, сәләтләрен һәм омтылышларын тагын да тулырак ачу өчен аларны дифференциацияләнгән укытуны оештыру исәбенә үткәрелә.

Төп гомуми белем алган чыгарылыш сыйныф укучылары укуларын республикада спектрлары шактый төрле булган мәктәпләрдә яки урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә.

Балаларга әхлакый һәм эстетик тәрбия бирүгә, танып-белү активлыгын үстерүгә һәм тәрбияләнүчеләрне иҗади яктан реализацияләүгә музыкаль дәресләр һәм өстәмә белем бирүнең башка төрләре ярдәм итә.»;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«IV. Җайлаштырылган программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер мәгариф оешмасы өчен җиһазлар исемлеген бирүгә алдан калькуляция ясау**

| Т/с | Җайлаштырылган гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы бер мәгариф оешмасы өчен акча тоту юнәлешләре | Суммасы, млн.сум |
|---|---|---|
| 1. | «Технология» предмет өлкәсе буенча хезмәт остаханәләре өчен;<br>педагог-психолог, укытучы-дефектолог, укытучы-логопед кабинетлары өчен;<br>сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән белем алучыларга өстәмә белем бирү өчен | 4,16 |
| Барлыгы | | 4,16.»; |

әлеге Концепциянең 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2019 – 2021 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәгарифкә ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру концепциясенә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 март, 113 нче
карары редакциясендә)

«Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында, дистанцион технологияләрне һәм челтәрле үзара бәйләнешләрдән файдаланып, гомуми белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренә методик ярдәм, балаларга һәм аларның ата-аналарына психологик-педагогик ярдәм күрсәтүче төбәк укыту-методик (ресурс) үзәге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең база исемлеге

| Т/с | Индикатор/күрсәткеч исеме | Белем бирү оешмаларының мәгънәләре, процент | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
| 1. | Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләре нигезендә педагогик хезмәткәрләр һәм белгечләр белән тәэмин ителеш | 100 | 100 | 100 |
| 2. | Белем алучыларның махсус белем бирү ихтыяҗларын исәпкә алып, индивидуаль белем бирү маршрутын тәэмин итә торган заманча сәламәтлек саклау мохите шартларын булдыру чаралары комплексын тормышка ашыру | 50 | 50 | 50 |
| 3. | Хезмәт базарында, шул исәптән «Кванториум» балалар технопарклары базасында таләп ителә торган һөнәрләр буенча «Технология» предметы өлкәсенең хезмәт һәм һөнәри-хезмәт укытуның заманча программаларын гамәлгә кертү чаралары комплексын тормышка ашыру | 100 | 100 | 100 |
| 4. | Белем алучыларны һөнәри юнәлеш бирү эше белән тәэмин итү | 100 | 100 | 100 |
| 5. | Педагогик хезмәткәрләрнең һәм белгечләрнең квалификациясен күтәрү (һөнәри яңадан әзерләү) | 100 | 100 | 100 |

_______________